**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ СПАССКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

«20» 05 2020 ел Болгар Ш. № 287

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Башкарма комитетының 05.03.2013 ел, № 145 карары белән расланган Муниципаль учреждение җитәкчесе вазыйфасына керүче зат, шулай ук муниципаль учреждение җитәкчеләренә үзләренең керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында һәм хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирү турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 275 статьясы, Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Башкарма комитетының 05.03.2013 ел, № 145 карары белән расланган Муниципаль учреждение җитәкчесе вазыйфасына керүче зат, шулай ук муниципаль учреждение җитәкчеләренә үзләренең керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында һәм хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирү турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә

1.1. Нигезләмәнең 2 пунктында «ел саен, хисап елыннан соң килүче елның 30 апреленнән дә соңга калмыйча» сүзләрен «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру өчен билгеләнгән срокларда ел саен» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Спас муниципаль районының рәсми сайтында http:/ www.spasskiy.tatarstan.ru, хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (//http:pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Спас муниципаль Районының башкарма комитеты җитәкчесе В.А. Осокин